

Рузаевка районы Татар Пешлә гомуми белем бирv урта мәктәбебезнен 8,9, 10 сыйныф укучылары белән укытучылары Альфия Шихап кызы Альшина һәм мин, Сания Спартак кызы Саляева, мавыктыргыч экскурсиягә юл тоттык; Ләмберә атлар абзарына бардык. Максатыбыз - балаларны атлар, аларнын яшәv шартлары белән таныштыру, аларга карата шәфкатьлелек хисләре, миһербанлылык тәрбияләv иде.
Без килгәндә, атларны утарга ашарга чыгарганнар иде. Безне кvргәч, акыллы хайваннар ашауларын ташлап, балалар янына жыелдылар. Барыбыз да сакланып кына vзебез алып килгән ипи телемнәре, шикәр белән аларны сыйладык, ялларын сыйпадык. Атлар рәхмәт әйткән кебек пошкырып башларын чайкагач, балаларнын шатлыклары эчләренә сыймады. Аннары атларга исемнәр сайладык, торак эченә кереп, атларны, нәни колыннарны, пониларны кvзәттек. Аларнын һәрберсенен исеме бар. Мәсәлән, Мэри, Граф, Кузя... Атлар караучы Клавдия апа балаларга инструктаж vткәрде. Ничек һәм кайсы яктан ат янына килергә, дилбегәне ничек тотарга, ат остендә ничек утырып торырга ойрәтте һәм кvрсәтте. Шуннан сон, жигеп ике ат алып чыктылар. Берсенен исеме - Мэри, икенчесенеке - Граф. Клавдия апа карамагында укучыларыбыз, хәтта укытучыларыбыз да, чиратлап атларга атланып йордек. Инструктор башта безгә берничә йорv элементларын кvрсәтте: галопом - сикертеп чабу, юыртып чабу - рысью. Укучыларга бу аралашу бик ошады. 10 сыйныф укучысы Ильдар Кузиков, Альбина Ларина, Амина Люркяева атларнын яныннан китәселәре дә килмәде; матурлыкларына сокланып озак карап тордылар бу малкайлар остенә. Татарларыбызга геннар биеклегендә бу хис таныш һәм якын. Ничек иттереп сокланмый узарга була бу матурлык янынннан!
Экскурсия балаларда унай тәэсирләр калдырды. Берничә бала тренировкага йорергә булдылар. Теләк белдерvчеләр арасында сигезенче сыйныф укучысы Рината Толстякова. Шат һәм кvп кенә унай эмоцияләр алып кайттык мавыктыргыч экскурсиядән без.

**Сания Саляева**